КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 февраль г.Казань № 65

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 март, 261 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 март, 261 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 24 октябрь, 1346 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы» сүзләреннән соң «, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибендә:

11 пунктта «131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясындагы $2^3$ – $2^5$ өлешләре нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясындагы 7 – 12 өлешләре нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Документтар тикшерүне оештыру вәкаләтле органның урнашу урыны буенча гамәлгә ашырыла.

Документтар тикшерүне үткәрү барышында, беренче чиратта, контрольдә тотылучы затның вәкаләтле орган карамагындагы документлары, шул исәптән үткән тикшерүләр актлары, административ хокук бозулар турында эшләрне карау нәтиҗәләре буенча материаллар һәм әлеге контрольдә тотылучы затка карата дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында башка документлар карала.

Әгәр вәкаләтле орган карамагындагы документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шикләр тудырса яисә әлеге белешмәләр контрольдә тотылучы зат тарафыннан гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрнең гамәлгә ашырылуын бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, вәкаләтле орган «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясындагы 16 – 19 өлешләренә таянып эш итә.

Бирелгән аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда вәкаләтле орган гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны бозу билгеләрен билгеләгән булса, вәкаләтле органның вазыйфаи заты күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Күчмә тикшерү предметы – контрольдә тотылучы затның документларындагы белешмәләр, шулай ук алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләрнең халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге таләпләргә туры килүе.

Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затның урнашу урыны һәм (яисә) эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны, шулай ук контрольдә тотылучы зат тарафыннан файдаланыла торган территорияләр, биналар, корылмалар һәм бүлмәләр урнашу урыны буенча үткәрелә.»;

19 пунктта «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеген план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр турында, аларның нәтиҗәләре һәм ачыкланган бозуларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү күрелгән чаралар турында мәгълүмат тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.»;

21 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле органның тикшерү үткәрүче вазыйфаи заты билгеләнгән форма буенча ике нөсхәдә акт төзи.

Тикшерү актына үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яки бәяләмәләре, контрольдә тотылучы затның вазыйфаи затларының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча ачыкланган бозулар турында аңлатмалары, бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин